Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
“83 нче санлы гомуми үстерешле балалар бакчасы”
бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе

# Балачак- уйнап- көлеп үсәр чак

Методик кулланма

Сахабиева Гөлүсә Җәмиловна

Бу **уеннар җыентыгын төзүнең максаты:** балаларны һәм ата-аналарны моңарчы бик үк билгеле булмаган, онытыла башлаган уен үрнәкләре белән таныштыру, заман таләпләренә яраклаштырып, бүгенге көн балаларына аларны җиткерү.

**РЕЦЕНЗИЯ**
**на методическое пособие по развитию речи посредством игры «Балачак - уйнап-көлепүсәрчак», педагогаМАДОУ «Детский сад общеразвивающего вида №83» Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан Сахабиевой Гелюсы Замиловны**

В настоящее время проблемы, связанные с процессом развития речи являются центральной задачей воспитания детей дошкольного возраста. Это, прежде всего, связано с социальной значимостью и ролью развития речи в формировании личности. Речь, являясь самостоятельным видом речемыслительной деятельности, вместе с тем выполняет важную роль в процессе воспитания и обучения детей, т.к. она выступает в виде средства получения знаний и средства контроля за этими знаниями.

Автор-разработчик рецензируемого пособия обоснованно рекомендует развитие речи дошкольников осуществлять в процессе ведущего вида деятельности –игры.

Особый методический интерес для практикующих педагогов представляет многообразие, представленных в пособии игр с подробным описанием методики проведения: развивающих, подвижных,танцевально-песенных, пальчиковых.

Дидактической ценностью является включение в пособие средств народной педагогики для развития речи дошкольников во время игры: загадок, скороговорок, считалок. При этом автор-разработчик опирается на закономерность об эффективности использования устного народного творчества в дошкольном учреждении для развития речи детей дошкольного возраста, так как содержание форм произведений словесного творчества народа, обусловлена характером знакомства с ними и речевым развитием дошкольников.

Использование материалов методического пособия в образовательном процессе позволяет комплексно решить ряд педагогических задач: развитие свободного общения детей с взрослыми посредством обучения отвечать на вопросы педагога, спрашивая и выражая свои впечатления и мысли, рассказывая о результатах своих наблюдений; развитие связной, грамматически правильной диалогической и монологической речи; развитие умение говорить перед группой сверстников.

Методическое пособие «Балачак - уйнап-көлепүсәрчак», соответствует требованиям федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования и рекомендуется к реализации в педагогической практике для успешного решения задач развития речи детей посредством игры.

Кандидат педагогических наук, доцент
зав. кафедры «Психология и педагогика»
НФ КИУ им. В.Г.Тимирясова Р.Ф. Гатауллина



**Үстерешле уеннар** – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе. Уен вакытында баланың сөйләме үсә, сүз байлыгы арта. Чөнки бала бу чакта күпләр белән бәйләнешкә керә, яңадан-яңа сүзләр ишетә һәм үзе дә аларны куллана.






**Ял минутлары** шулай ук баланың сәламәтлеге өчен мөһим. Ник дигәндә, алар бик тиз аралар, тизрәк уйныйсылары килә башлый, талчыгалар. Ял минутлары кирәкле вакытта уздырылса, балалар армаячак һәм үзләрен кирәкле дәрәҗәдә тотачаклар.






**Хикәяләү** – эчтәлек сөйләүгә караганда катлаулы эшчәнлек. Бала өчен материалны системалаштыру, план буенча сөйләү җитди бурыч булып тора. Балага хикәясенең кирәклеген төшендерергә, аның сүзләрен куәтләргә, хупларга кирәк. Бала үзенең хикәясеннән канәгатьләнү алырга,сөйли белүен тоеп, шатлык хисе кичерергә тиеш.





Балаларны кул чукларын һәм бармакларын хәрәкәтләндерергә, җитезлекне арттырырга өйрүнүдә **“бармаклы уен”нар** зур урын алып тора. Бу хисле – тойгылы һәм мавыктыргыч уен. Ул әйләнә – тирәдәге чынбарлыкны, әйберләрне,җәнлекләрне,кешеләрне, аларның эшчәнлеген,табигать күренешләрен чагылдыра. Мондый уеннар барышында балалар, өлкәннәр ни эшләсә,шуны кабатлап, кулларын тиз-тиз хәрәкәтләндерәләр һәм бу җитезлекне арттыруга уңай йогынты ясый. Соңыннан сүзләрне үзләре өйрәнеп бетергәч, балаларга уйнавы тагын да күңелле була.





**Жырлы – биюле уеннар**– балаларда җыр эчтәлегенә һәм музыканың характерына туры китереп, хәрәкәт итү күнекмәләрен формалаштыру; җыр һәм биюләрне мөстәкыйль рәвештә башкарырга омтылыш булдыру; халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру һәм аларга карата мәхәббәт тәрбияләү. Уен вакытында балалар көй ритмына хәрәкәтләнәләр, дәртләнеп җырлыйлар, бииләр. Уеннар музыкаль авазларны тоемларга ярдәм итә, бала күңелендә нәфислек, матурлык тойгысы уята.





**Сүзле- хәрәкәтле уенар**, бер яктан, физик тәрбия чарасы булса, икенче яктан күп кенә уенар эстетик тәрбия бирүгә зур ярдәм итә. Хәрәкәтләрнең төгәллеге, уенның сүзләрен сәнгатле итеп әйтү, балаларның төрле образлар башкарулары- болар барысы да балаларда канәгатьләнү хисләре уята, матурлыкны аңларга ярдәм итә.



